| СОВЕТ КАНАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

19.09.2017 д. Канаш №29-128

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст. 1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Канаш авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә

Югары Ослан муниципаль районының
Канаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Канаш авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның түбәндәге мәсьәләләр буенча уртак инициативасын чыгарырга:

«2018 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегенең һәр кешесеннән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчалар юлламасына ризалыгыгыз бармы:

1. Канаш авылы Үзәк урамындагы 150 метр озынлыктагы җирле әһәмияттәге юллар төзелеше һәм вак таш өслекле керү юлын төзү, Зеленая урамында -20 метр су үткәргеч торба урнаштырып
2. Түбән Күл авылы Боевая урамы буенча вак таш өслекле 250 метр озынлыктагы юллар төзелеше
3. Йолдыз авылы Меминка елгасы аша күперне реконструкцияләү өчен төзелеш материалы сатып алу

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы: Н.Н. Вальков